ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

«20» июнь 2016 ел № 7/1

Киткән хатаны төзәтү турында

Күзкәй авыл җирлегенең 2016 елның 4 февралендәге 3/1 номерлы карарының 2 өлешендә, 2016 елның 27 мартындагы 6/12 номерлы карарының 2 өлешендә киткән хаталар белән бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Күзкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2016 елның 1 февралендәге 18 номерлы карары, Күзкәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 2 февралендәге 2/1 номерлы карары, Күзкәй авыл җирлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. «Җирле референдум билгеләү турында» 2016 елның 4 февралендәге 3/1 номерлы карарның 2 өлеше «в» пунктын түбәндәгечә укырга:

в) Иске Байлар авылындагы чишмәне төзекләндерү - 49050 сум,

2. «Җирле референдум нәтиҗәләре турында» 2016 елның 27 мартындагы 6/12 номерлы карарның 3 өлешен түбәнәдгечә укырга:

3) Иске Байлар авылындагы чишмәне төзекләндерү - 49050 сум,

3. Әлеге карарны «Якты юл»-«Светлый путь» газетасында бастырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Э.Р. Гәрәев